# КАРАР

**“25” ноябрь 2024 ел** **№ 14**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Югары Мәтәскә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

« Сез 2025 елда Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Мәтәскә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Югары Мәтәскә авылы, Азин урамы)?

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) 197 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 100 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 96 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Югары Мәтәскә авылында халык җыенын булып узган дип таныгра, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.
2. Сез 2025 елда Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Мәтәскә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән

балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Югары Мәтәскә авылы, Азин урамы)?

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Югары Мәтәскә авылы, Азин урамы, 31 йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Лутфуллин Ф.Ф.